КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1251

Шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга тимер юл транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга тимер юл транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Тимер юл һәм су транспорты өлкәсендә аерым чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1036 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тимер юл һәм су транспорты өлкәсендә аерым чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1036 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 31 май, 423 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тимер юл һәм су транспорты өлкәсендә аерым чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы

бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1036 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 29 март, 282 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тимер юл һәм су транспорты өлкәсендә аерым чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1036 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 20 гыйнвар, 25 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тимер юл һәм су транспорты өлкәсендә аерым чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1036 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 29 март, 1738 нче.

3. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин